Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының
Гаделша авыл җирлеге башлыгы
Карары

2020 елның 12 ноябре №7

«Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Чистай муниципаль районы Гаделша авыл җирлегенең Татар Гаделшасы авылында гражданнар җыенын билгеләү турында»

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Чистай муниципаль районының «Гаделша авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең 22 статьясы нигезендә

КАРАР БИРӘМ:

1. 2020 елның 26 ноябрендә 11.00 сәгатькә Гаделша авылы мәдәният йортында Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Гаделша авыл җирлегенең Татар Гаделшасы авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын түбәндәге адрес буенча билгеләргә: Татарстан Республикасы, Чистай районы, Татар Гаделшасы авылы, Сатдаров ур., 32 нче йорт.
2. 2020 елның 26 ноябрендә 12.00 сәгатькә авыл клубы йортында Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Гаделша авыл җирлегенең Татар Гаделшасы авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын түбәндәге адрес буенча билгеләргә: Татарстан Республикасы, Чистай районы, Татар Гаделшасы авылы, Сатдаров ур., 32 нче йорт.
*3.* Гражданнарның этаплап җыенын үткәрү өчен Татарстан Республикасы Гаделша авыл җирлегенең Татар Гаделшасы авылында яшәүчеләр исемлеген 2 өлешкә бүләргә:
   1) Мәктәп ур., Речная ур., Колхоз ур., Г.Тукай ур., Озерная ур.;
   *2)* Садовая ур., Яңа ур., Сатдаров ур.
4. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:

«2021 елда Чистай муниципаль районы Гаделша авыл җирлегенең Татар Гаделшасы авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән үзара салым кертүгә, 500 сум күләмендә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән ризалашасызмы:

**-** авыл эчендәге чокырлы юлларны ремонтлау (вак таш сатып алу, китерү, салу, килешү буенча эш өчен түләү);

- балалар уен мәйданчыгы сатып алу, урнаштыру, балалар уен мәйданчыгы территориясен төзекләндерү (материал, коймалар сатып алу, килешү буенча эш өчен түләү)

« РИЗА» «КАРШЫ».

5. Җыенны оештыручы итеп Чистай муниципаль районының Гаделша авыл җирлеге Башкарма комитетын билгеләргә.
6. Чистай муниципаль районының Гаделша авыл җирлеге башлыгының «Чистай муниципаль районының Гаделша авылы җирлегенең Татар Гаделшасы авылында гражданнар җыенын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча җыелыш билгеләү турында» 2020 елның 30 октябрендәге 4 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.
7. Әлеге карарны авыл җирлегендә яшәүчеләрне күпләп җыелган урыннарда, игълан итү стендларында һәм такталарында элү юлы белән игълан итәргә, шулай ук Чистай муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-коммуникация челтәрендә урнаштырырга.

Чистай муниципаль районының
Гаделша
авыл җирлеге башлыгы ________ И.А.Нуретдинов